**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

**18.01.2022 ел** **№1**

**2022 елга Турай авыл җирлегенең эш планын раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының "Турай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Турай авыл җирлегенең эш планын расларга (кушымта )
2. Әлеге карарны җәмәгать урыннарында мәгълүмат стендларында, шул исәптән Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:mendeleevsk.tatarstan.ru урнаштырып халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Турай авыл җирлеге башлыгы: А.М.Рәхимова

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварендагы 1 номерлы карарына кушымта

# Эш планы

| № гг\п | Чаралар исеме | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хокукый актларын әзерләү | ел дәвамында | Вәлиева Л.Н. |
| 2. | Район администрациясе, башка оешмалар һәм учреждениеләр белән үзара хезмәттәшлек | район хакимияте планы нигезендә | Рәхимова А.М |
| 3, | Гражданнарны шәхси сораулары буенча кабул итү | эш регламенты нигезендә | Рәхимова А.М.<br>Турай авыл җирлеге Советы депутатлары |
| 4. | Авыл җыеннарын оештыру һәм уздыру | план буенча ел дәвамында | Валиева Л.Н.<br>Рәхимова А.М |
| 5. | Авыл җирлеге Советы утырышларын үткәрү | кирәк булган саен | Рәхимова А.М. |
| 6, | Муниципаль хезмәткәрләр һәм депутатлар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү. | гыйвар-март | Вәлиева Л.Н.<br>Рәхимова А.М |
| 7. | Массакүләм бәйрәмнәр оештыру<br><br>1. Ватанны саклаучылар көне;<br>2. Халыкара хатын-кызлар көне;<br>3. Май чабу<br>4. 1 май<br>5. Җиңү көне<br>6. Сабантуй<br>7. Россия көне<br>8. Халык бердәмлеге көне<br>9. Өлкәннәр көне<br>10. Әниләр көне<br>11 Инвалидлар декадасы<br>12. Яңа ел | | Вәлиева Л.Н.<br>Рхимова А.М<br>Мөхәмәтхатипова Ф.Ш.<br>Хикмәтов Р.Р.<br>Салихова Л.М.<br>Бәйрәмгалиева З.М. |
| 8. | Бюджет оешмалары җитәкчеләре белән планеркалар | Һәр сишәмбе | Рәхимова А.М. |
| 9. | Турай авыл җирлеге сайтын мәгълүмат ресурслары белән тутыру эшен гамәлгә ашыру. | кирәк булган саен | Вәлиева Л.Н. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Террорчылыкны һәм экстремизмны ачыклау һәм кисәтү буенча халык арасында аңлату эшләре алып бару | даими | Вәлиева Л.Н.<br>Рәхимова А.М<br>Мөхәмәтхатипова Ф.Ш.<br>Хикмәтов Р.Р.<br>Салихова Л.М.<br>Бәйрәмгалиева З.М. |
| 11. | Имин булмаган балалы гаиләләргә рейдлар | ел дәвамында | Вәлиева Л.Н.<br>Рәхимова А.М<br>Мөхаметхатипова Ф.Ш.<br>Хикмәтов Р.Р.<br>Салихова Л.М.<br>Бәйрәмгалиева З.М. |
| 12. | Сугыш һәм хезмәт ветераннарының, өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш шартларын тикшерү буенча рейдлар | Квартал саен | Рәхимова А.М.<br>социаль хезмәткәрләр |
| 13. | Бюджет-финанс эше | ел дәвамында | Рәхимова А.М. |
| 14. | Шәхси ярдәмче хуҗалык белешмәләрен хуҗалык исәбе белешмәләре белән чагыштыру, ЭПХ тутыру | ел дәвамында | Вәлиева Л.Н. |
| 15. | Турай авыл җирлеге территориясен чистарту буенча санитар - экологик икеайлык | Апрель-май | Рәхимова А.М.<br>бюджет учреждениеләре җитәкчеләре |
| 16. | Зират территориясен җыештыру | май-сентябрь | Рәхимова А.М. |
| 17. | Юлларны кардан чистартуга шартнамәләр төзү | январь | Рәхимова А.М. |
| 18. | Архив фондларын формалаштыру чаралары | ел дәвамында | Вәлиева Л.Н. |
| 19. | Район чараларында катнашу | чаралар уздыру планы нигезендә | |